**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 7 июль | № 463

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләүне оештыру турында» 2016 ел, 20 май, 331 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләүне оештыру турында» 2016 ел, 20 май, 331 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкның барлык категорияләрен әзерләү һәм бу өлкәдә белемнәрне пропагандалау өчен массакүләм мәгълүмат чараларын файдаланырга, шулай ук «Бөтенроссия дәүләт телевизион һәм радио тапшырулары компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы «Татарстан» дәүләт телевизион һәм радио тапшырулары компаниясенә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга файдаланырга тәкъдим итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков